КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 20 февраль г.Казань № 98

Халыкара һәм бөтенроссия спорт ярышларында югары уңышларга ирешкәннәре өчен спортчыларга һәм тренерларга дәүләт ярдәме күрсәтү турында

Олимпия, Паралимпия, Сурдлимпия уеннарында һәм башка халыкара һәм бөтенроссия спорт ярышларында катнашуга әзерлек чорында спортчыларга һәм тренерларга дәүләт ярдәме күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Механизмга теркәлгәннәрне расларга:

спортта югары уңышлары өчен Татарстан Республикасының әйдәүче спортчыларына айлык стипендияләр күләмнәре;

спортта югары нәтиҗәләр күрсәткән спортчылар әзерләгән өчен Татарстан Республикасы тренерларына айлык өстәмә түләүләр күләмнәре;

спортта югары уңышлары өчен Татарстан Республикасының әйдәүче спортчыларына һәм аларның тренерларына премиаль бүләкләүләр күләмнәре.

2. Әлеге карарны тормышка ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслау билгеләнгән тәртиптә тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына расланган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет лимитлары кысаларында гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына 60 көн эчендә спортта югары уңышлары өчен Татарстан Республикасының әйдәүче спортчыларына айлык стипендияләрне һәм аларның тренерларына айлык өстәмә түләүләрне билгеләү, бирүне туктатып тору һәм бирмәү тәртибен эшләргә һәм расларга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы спортчыларына һәм тренерларына дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2010 ел, 19 гыйнвар, 17 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы спортчыларына һәм тренерларына дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2010 ел, 19 гыйнвар, 17 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 16 гыйнвар, 14 нче.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 20 февраль, 98 нче
карары белән расланды

**СПОРТТА ЮГАРЫ УҢЫШЛАРЫ ӨЧЕН**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ӘЙДӘҮЧЕ СПОРТЧЫЛАРЫНА**
**АЙЛЫК СТИПЕНДИЯЛӘР КҮЛӘМНӘРЕ**

| **Ярышлар исеме** | **Айлык стипендияләр күләме (сум)** | | |
|---|---|---|---|
| | **I урын** | **II урын** | **III урын** |
| Олимпия, Паралимпия һәм Сурдлимпия уеннары | 90 000 | 70 000 | 50 000 |
| Дөнья чемпионаты | 60 000 | 50 000 | 40 000 |
| Европа чемпионаты | 50 000 | 40 000 | 30 000 |
| Яшүсмерләр олимпия уеннары, дөнья беренчелеге | 30 000 | 25 000 | 20 000 |
| Европа яшүсмерләр Олимпия фестивале, Европа беренчелеге | 25 000 | 20 000 | 15 000 |
| Россия чемпионаты | 20 000 | 15 000 | 10 000 |
| Россия беренчелеге (яшьләр, юниорлар), Россия яшьләре спартакиадасы | 10 000 | 7 500 | 5 000 |
| Россия беренчелеге (14 яшьтән һәм өлкәнрәк егетләр һәм кызлар), Россия укучылары спартакиадасы | 5 000 | 3 700 | 2 500 |

Искәрмәләр:

1. Россия Федерациясе спорт министрлыгының Төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара физкультура чаралары һәм спорт чараларының бердәм календарь планына кертелгән халыкара һәм бөтенроссия спорт ярышларында, спортның олимпия булмаган төрләре буенча, шулай ук спортның Олимпия, Паралимпия һәм Сурдлимпия уеннары программаларына керми торган олимпия, паралимпия һәм сурдлимпия төрләре дисциплиналары буенча призлы урыннарны алган спортчыларга айлык степендияләр әлеге раслаган стипендияләр күләменең 25 проценты күләмендә түләнә.

2. Айлык стипендияләр узган календарь елы йомгаклары буенча спортчы күрсәткән иң югары бер нәтиҗә өчен бер календарь елы дәвамында түләнә.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 20 февраль, 98 нче
карары белән расланды

**СПОРТТА ЮГАРЫ НӘТИҖӘЛӘР КҮРСӘТКӘН СПОРТЧЫЛАР ӘЗЕРЛӘГӘН ӨЧЕН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТРЕНЕРЛАРЫНА АЙЛЫК ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮЛӘР КҮЛӘМНӘРЕ**

| **Ярышлар исеме** | **Олимпия, Паралимпия һәм Сурдлимпия уеннары** | | | **Чемпионаты мира** | | | **Чемпионаты Европы** | | | **Чемпионаты России** | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Алынган урын | I урын | II урын | III урын | I урын | II урын | III урын | I урын | II урын | III урын | I урын | II урын | III урын |
| Өстәмә түләүләр күләме, сум | 15 000 | 12 500 | 10 000 | 10 000 | 9 000 | 8 000 | 7 000 | 6 000 | 5 000 | 4 000 | 3 000 | 2 000 |

Искәрмәләр:

1. Тренерларга айлык өстәмә түләүләр бер календарь елы дәвамында башкарыла һәм узган календарь елы йомгаклары буенча бер спортчы ярышларның бер төрендә шәхси дисциплиналарда күрсәткән иң югары бер нәтиҗә өчен билгеләнә.
2. Төркем дисциплиналарда һәм спортның команда төрләрендә һәр чираттагы спортчы (төркем яки команда) өчен билгеләнгән күләмнәрнең 10 проценты күләмендә өстәмә түләү башкарыла.
3. Олимпия, Паралимпия һәм Сурдлимпия уеннары программаларына керми торган олимпия, паралимпия һәм сурдлимпия төрләре дисциплиналары буенча түләүләр билгеләнгән күләмнең 75 проценты күләмендә башкарыла.
4. Спортның Олимпия, Паралимпия һәм Сурдлимпия уеннары программаларына керми торган төрләре буенча түләүләр билгеләнгән күләмнең 50 проценты күләмендә башкарыла.

________________________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 20 февраль, 98 нче
карары белән расланды

# СПОРТТА ЮГАРЫ УҢЫШЛАРЫ ӨЧЕН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ӘЙДӘҮЧЕ СПОРТЧЫЛАРЫНА ҺӘМ АЛАРНЫҢ ТРЕНЕРЛАРЫНА ПРЕМИАЛЬ БҮЛӘКЛӘҮЛӘР КҮЛӘМНӘРЕ

| **Ярышлар исеме** | **Акчалата бүләкләүләр (сум)** | | |
|---|---|---|---|
| | **I урын** | **II урын** | **III урын** |
| Олимпия, Паралимпия һәм  Сурдлимпия уеннары | 4 000 000 | 2 500 000 | 1 700 000 |
| Дөнmя чемпионаты | 150 000 | 90 000 | 60 000 |
| Европа чемпионаты | 70 000 | 50 000 | 30 000 |
| Россия чемпионаты | 12 000 | 10 000 | 6 000 |

Искәрмәләр:

1. Россия Федерациясе спорт министрлыгының Төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара физкультура чаралары һәм спорт чараларының бердәм календарь планына кертелгән   халыкара һәм бөтенроссия спорт ярышларында, спортның олимпия булмаган төрләре буенча, шулай ук спортның Олимпия, Паралимпия һәм  Сурдлимпия уеннары программаларына керми торган олимпия, паралимпия һәм сурдлимпия төрләре дисциплиналары буенча спортта ирешкән уңышлар өчен премиаль бүләкләүләр билгеләнгән нормативларның  күләменең 25 проценты күләмендә түләнә.

2. Халыкара һәм бөтенроссия спорт ярышларында җиңүчеләрне һәм призерларны тәрбияләүдә һәм әзерләүдә катнашкан тренерларга премиаль бүләкләүләр спортчыны бүләкләү  суммасының 50 проценты күләмендә түләнә.

3. Спортчыларга һәм тренерларга  премиаль бүләкләүләр  бер тапкыр, ярышларда күрсәтелгән бер югары нәтиҗә өчен түләнә.